**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О налоге на имущество организаций»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2024 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 ноября 2003 года № 49-ЗРТ «О налоге на имущество организаций» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 июля 2010 года № 51-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 11; 2010, № 7 (II часть); 2011, № 5, № 8 (I часть); 2012, № 2, № 6 (I часть); 2013, № 3, № 6 (II часть), № 10, № 12 (I часть); 2014, № 10 (I часть); 2015, № 6 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2017, № 1 (часть I), № 17 (часть I), № 50 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 54 (часть I); 2019, № 49 (часть I); 2020, № 26 (часть I), № 57 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 36 (часть I), № 49 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 3 (часть I), № 34 (часть I), № 49 (часть I), № 77 (часть I), № 90 (часть I); 2023, № 48 (часть I), № 56 (часть I), № 73 (часть I); 2024, № 45 (часть I) следующие изменения:

1) часть 1 статьи $1^1$ изложить в следующей редакции:
«1. Налоговая база в отношении административно-деловых центров и торговых центров (комплексов) общей площадью свыше 1000 квадратных метров и помещений в них определяется как их кадастровая стоимость, утвержденная в установленном порядке.»;

2) часть 3 статьи 2 изложить в следующей редакции:
«3. Налоговая ставка в отношении объектов недвижимого имущества, налоговая база в отношении которых определяется как кадастровая стоимость, устанавливается в размере 2 процентов.»;

3) в статье 3:

а) дополнить частью $3^2$ следующего содержания:

«$3^2$. Налог уплачивается в размере 60 процентов исчисленной суммы налога в отношении объектов недвижимого имущества, указанных в части 1 статьи $1^1$ настоящего Закона, за исключением торговых центров (комплексов) общей площадью свыше 2000 квадратных метров и помещений в них, расположенных на территориях населенных пунктов с численностью населения более 145 тысяч человек.»;

б) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. Налоговые льготы, установленные частями 1 – $3^1$ настоящей статьи, не предоставляются налогоплательщикам в отношении объектов недвижимого имущества, налоговая база в отношении которых определяется как кадастровая стоимость.»;

4) статью 5 дополнить пунктом 13 следующего содержания:

«13) с 1 января 2028 года часть $3^2$ статьи 3 настоящего Закона.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2025 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан ____________ Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
26 июля 2024 года
№ 66-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1^1$ статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата салым базасы аларның билгеләнгән тәртиптә расланган кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә.»;

2) 2 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата салым ставкасы 2 процент күләмендә билгеләнә.»;

3) 3 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^{2}$. Салым әлеге Законның $1^{1}$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән күчемсез милек объектларына карата исәпләнгән салым суммасының 60 проценты күләмендә түләнә, халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар моңа керми.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым түләүчеләргә әлеге статьяның 1 – $3^{1}$ өлешләрендә билгеләнгән салым ташламалары салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата бирелми.»;

4) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) 2028 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясының $3^{2}$ өлешен.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 66-ТРЗ